КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 48

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмалар белән идарә итүнең бердәм органын билгеләү турында

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, шулай ук яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан чараларны тормышка ашыруга карата таләпләрне һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмаларга карата таләпләрне раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 67 нче боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 ел, 14 февраль, 67 нче боерыгы) белән расланган Кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, шулай ук яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан чараларны тормышка ашыруга карата таләпләрнең һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмаларга карата таләпләрнең 8.1 нче пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясен, аңа Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 ел, 14 февраль, 67 нче боерыгы белән расланган расланган Кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү өчен, шулай ук яшьләр эшмәкәрлегенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан

чараларны тормышка ашыруга карата таләпләрнең һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмаларга карата таләпләрнең 8.1 нче пунктында күрсәтелгән функцияләрне биреп, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын булдыра торган оешмалар белән идарә итүнең бердәм органы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин